КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 ноябрь г.Казань № 1034

Юридик затларның азык-төлек продуктлары җитештерү максатларында арпа сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Юридик затларның азык-төлек продуктлары җитештерү максатларында арпа сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 1 ноябрь, 1034 нче
карары белән расланды

Юридик затларның азык-төлек продуктлары җитештерү максатларында
арпа сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип юридик затларның азык-төлек продуктлары (эчемлекләрне кертеп) җитештерү максатларында агымдагы финанс елында арпа сатып алу чыгымнарының бер өлешен (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – шул ук эзлеклелектә сайлап алуда катнашучы, азык-төлек продуктлары, субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия бирүнең максаты – Татарстан Республикасы территориясендә тормышка ашырыла торган, агросәнәгать комплексын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә азык-төлек продуктлары җитештерү өчен арпа эшкәртү эшчәнлеген үстерүгә икътисадый уңай шартлар тудыру.

3. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) бюджет акчасын алучы буларак бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Субсидия турында мәгълүматлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда Министрлык тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

5. Субсидия алучылар Министрлык тарафыннан, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашучылар җибәргән тәкъдимнәрне (заявкаларны) (алга таба – заявкалар) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

6. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч

календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән ким була алмаган сайлап алуны үткәрү срокларын (заявкалар бирү (кабул итү) башлану (тәмамлану) датасын һәм вакытын);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 17 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итәлә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 7 һәм 8 пунктлары нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата критерийларны һәм таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 9 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкаларга үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 10 һәм 11 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләрен бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак була алмаган урнаштыру датасын.

7. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

Татарстан Республикасы территориясендә бу Тәртип нигезендә субсидия бирү елына кадәрге финанс елы йомгаклары буенча азык-төлек продуктлары җитештерү максатларында арпа эшкәртү кимендә 80 мең тонна күләмендә.

8. Сайлап алуда катнашучы заявка биргән датага кадәр 15 эш көненнән дә артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча

вакытында түләнмәгән бурычлар, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлар булмый;

үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка кушу, башка юридик зат рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булып тормау;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау.

9. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы бирә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм тиешле сайлап алуга бәйле сайлап алуда катнашучы турындагы башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) сайлап алуда катнашучының ризалыгы бирелгән, үзенең түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада булган заявка;

заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтындагы Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

салым органының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган, заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән белешмә кәгазе (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмә кәгазе;

арпа кайтарту (сатып алу-сату) шартнамәләренең күчермәсе;

арпа сатып алуга счет-фактуралар һәм товар йөкнамәләренең күчермәсе;

сатып алынган арпа өчен түләүгә тотылган чыгымнарны раслый торган түләү йөкләмәләренең күчермәсе;

субсидия бирү елына кадәрге финанс елы йомгаклары буенча Татарстан

Республикасы территориясендә азык-төлек продуктлары җитештерү максатларында арпа эшкәртү күләмнәре турында мәгълүмат;

агымдагы финанс елына кадәрге ел өчен авыл хуҗалыгы чималыннан җитештерелгән беренчел һәм сәнәгать эшкәртүендәге продукция җитештерү, аның чыгымнары, үзкыйммәте һәм аны сату турында һәм азык-төлек продуктлары җитештерү максатларында Татарстан Республикасы территориясендә эшкәртелгән арпа күләмен раслый торган хисап һәм агымдагы финанс ел йомгаклары буенча планлаштырыла торган табыш турында ирекле формадагы мәгълүмат.

Тапшырылган документларның күчермәсе сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан таныкланган, документларга имзалары куелган һәм мөһер (булганда) белән расланган булырга тиеш.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка кергән көнендә чират тәртибендә теркәүгә алына.

10. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән сайлап алуны үткәрү срогы эчендә заявкаларны, аларның керү датасын һәм кергән көндәге вакытын күрсәтеп, «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы» мәгълүмат системасында терки;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән сайлап алуны үткәрү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә тапшырылган заявкаларның һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча сайлап алу нәтиҗәләре турында (сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү йә заявканы кабул итүдән баш тарту турында) реестр төзи һәм раслый;

сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

11. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявкаларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга

карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

заявканың сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявка бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән критерийларга туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитының сарыф итеп бетерелүе.

12. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән 10 эш көне эчендә субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә килешү төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, күчерү тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе;

субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару тәртибе;

субсидия алучы тарафыннан Министрлык билгеләгән өстәмә хисапларны бирү формасы һәм сроклары;

моңа кадәр җиткерелгән, бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын Министрлыкка субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә биреп булмауга китерә торган дәрәҗәдә киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча уртак фикергә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында шарт.

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

13. Бу Тәртипнең 12 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән срокларда килешүгә субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның имза куюын тәэмин итмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

14. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән килешүләр төзүне төгәлләү срогы көненнән бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы белән рәсмиләштерелә торган субсидия алучыларга субсидия бирү турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

15. Чыгымнарны каплау өчен субсидия бирелә торган әлеге чыгымнар юнәлешләре – агымдагы финанс елында азык-төлек продуктлары җитештерү өчен файдаланыла торган арпа сатып алуга фактта башкарылган чыгымнар (өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарыннан тыш).

16. Субсидия күләме (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча) ($S_z$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_z = \sum (P_z \times n_z) \times 0,95,$$

монда:

$P_z$ – арпа кайтарту (сатып алу-сату) турындагы һәр шартнамә буенча 1 тонна арпа кыйммәте (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча), әмма 1 тонна арпа өчен иң күбе 13 мең сум (өстәлгән кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча);

$n_z$ – агымдагы финанс елында сатып алынган арпа күләме, тонна.

17. Субсидия бирү нәтиҗәсе – субсидия бирү елыннан соң килә торган елның 1 декабренә кадәр субсидия бирү елының 1 декабреннән башланган чорда (алга таба – хисап чоры) сатып алу чыгымнарын каплау өчен агымдагы финанс елында субсидия бирелгән, сатып алынган арпаны эшкәртү күләме.

Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән нәтиҗә мәгънәсен субсидия бирү елыннан соң килә торган елның 1 декабре хәленә карата нәтиҗәнең фактта ирешелгән мәгънәсе белән чагыштырып карау нигезендә бәяләнә.

18. Субсидия алучы субсидия бирү елыннан соң килә торган елның 15 декабренә кадәр Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасы буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап тапшыра.

Субсидия алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 енә кадәр, Министрлыкка сатып алу чыгымнарын каплау өчен агымдагы финанс елында субсидия бирелгән, сатып алынган арпаны эшкәртү күләме турында ирекле формадагы өстәмә хисаплылык кертә.

19. Субсидия Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

алучы тарафыннан субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар бирелгәндә, субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән, шул исәптән субсидиядән файдаланганда шартлар бозылганда, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булганда – тулы күләмдә;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр турында хисап һәм өстәмә хисаплылык тапшырмаганда, шулай ук әлеге хисапларны тапшыру сроклары бозылганда – тулы күләмдә;

бу Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәгәндә – килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсеннән тайпылуга пропорциональ билгеләнә торган күләмдә.

20. Субсидия алучы бу Тәртипнең 17 пунктында билгеләнгән нәтиҗә мәгънәсенә ирешмәгән очракта, Министрлык әлеге факт билгеләнгән көннән 10 көн эчендә субсидия алучыга түбәндәге формула буенча күләме билгеләнә торган субсидиянең бер өлешен кире кайтару турында таләп җибәрә:

$$S_{vozvr} = S_z \times (1 - k),$$

монда:

$S_{vozvr}$ – кире кайтарылырга тиешле субсидия суммасы, сум;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүнең түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициенты:

$$k = \frac{V_{fakt}}{V_{plan}},$$

монда:

$V_{fakt}$ – сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидия бирелә торган арпаның хисап чорында фактта эшкәртелгән күләме, тонна;

$V_{plan}$ – сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидия бирелә торган арпаның хисап чорында эшкәртелергә тиеш булган, сатып алынган арпа күләме, тонна.

21. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 19 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрә.

22. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучыларның субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

23. Субсидия алучы тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучыларның тиешле вазыйфаи затларына йөкләнә.

24. Бюджет акчасыннан файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---